**Хөснетдинов Дамир Хайдарович**

Татар дәүләт гуманитар-педагогика университеты

# Татар телендә “Җир” концепты
## (Г. Бәшировның “Гыйбрәт” романы нигезендә)

Тел – һәр халыкның зур байлыгы. Ул халыкның мәдәниятен, көнкүрешен, тарихын чагылдыручы. Тел мәдәният белән тыгыз бәйләнешкә керә: ул аның эчендә үсә, аны чагылдыра, мәдәниятнең гомуми үсеше өчен зарури алшарт булып тора. Тел мәдәниятнең предмет-төшенчә характерындагы телдә теркәлмәгән эчтәлеген гәүдәләндерүче тормышка ашырылган “эчке форма” сыйфатында чыгыш ясый. Телне иң мөһим аралашу һәм фикерне чагылдыру чарасы буларак, мәдәният турындагы белемнәрне туплау вазыйфасыннан башка күз алдына да китереп булмый. Мәдәниятнең күпбаскычлы системасында тел, үзенең табигате, яшәү ысулы һәм потенциаль мөмкинлекләренә таянып, аерым урын алып тора һәм яшәүнең, аңлау-төшенүнең, үсешнең ысулы булып кала.

Тел белеменең чагыштырмача яңа, бүгенге көндә киң үсеш алган лингвокультурология тармагы телне мәдәният белән тыгыз бәйләнештә өйрәнүне максат итеп куя. Ягъни, мәдәниятнең байлыгы, күләме телдә чагыла. Лингвокультурологиянең төп төшенчәсе булып концепт санала.. Аның турында күп санлы фәнни карашлар урнашуга карамастан, аны тикшерү бүген дә актуаль проблема булып тора. Концепт – ул кеше аңындагы теге яки бу күренеш турында тупланган белемнәр, күзаллаулар, төшенчәләр, кичерешләр, ассоциацияләр җыелмасы, мәгълүмати конструкт [Степанов 1997: 40]. Концепт – катлаулы һәм күп билгеләмәле структура. Без карап үтә торган “ҖИР” концепты да үзенчәлекле, чөнки ул күп мәгънәле сүз берәмлеге буларак аерылып тора.

Татар теленең аңлатмалы сүзлегендә “ҖИР” концептының берничә төрле мәгънәсе бирелә.  Шуларның кайберләренә игътибар итик:

1. Кемнең дә булса биләмәсе, аерым кеше яки оешма, коллектив хуҗалыгындагы урман, болын, чәчүлек мәгънәсендә.

*— Моннан ике-өч ел элек безнең Килдебәккә, бик шәп тарантаска утырып, зәңгәр фуражкалы бер абый килде. Мыегы менә мондый! Үзе гел челем суыра. Зәмләмир, диделәр. Шул килеп киткәннән соң, безнең әниләргә, апаларга да җир бирә башладылар.*[Г. Бәширов, 2000: 52].

*—Беләсең ич инде, хөррият булгачыннан дөньялар зерә дә үзгәрде, бөтенләй яңача булып китте, димәсәң. Староста урынына Сәвит булды, хатын-кыз җир алды... тагын шундыйлар. Беләсеңме, безнең әтине нәрсә бик борчый? Ул, халык бозылыр, әшәкелек артыр, әдәпсезлек башланыр, дип бик курка* [Г. Бәширов, 2000: 207].

2. Әйбернең нинди дә булса бер өлеше, урыны, кисәге; кешенең нинди дә булса органы, кеше гәүдәсенең, тәненең бер өлеше:

*«Элек тә юк иде гаделлек, хәзер дә юк! Булмас та!» диде. Беләсегез килсә, иң авырттырган җиргә килеп бәрелгәне менә шушы булды. Алайсам нигә революция ясадык соң без, нигә сугышларда кан койдык?!* [Г. Бәширов, 2000: 152].

*Фәһимнең иң авырткан җиренә китереп бәрде бу хәбәр. Ул, ризасызлыгын белдереп, башын чайкап торды* [Г. Бәширов, 2000: 136].

Күргәнебезчә, Гомәр Бәширов кеше гәүдәсенең, тәненең бер өлеше мәгънәсендә килгән «җир» сүзен башлыча *авырткан җир* сүзтезмәсе составында кулланган.

3. Туып-үскән ил, туган ил мәгънәсендә автор «җир» сүзен җиде тапкыр файдалана. Түбәндәге мисалларда «җир» сүзе белән күпчелек очракта *туган* эпитеты килгән:

*— Салындырма борынны, сеңелкәй! Кеше бит син, кеше кадәр кеше! Беләсенме, кеше булгач, аның туган җире дә булырга тиеш! Кеше туган җирсез була алмый!* [Г. Бәширов, 2000: 106].

*Кеше туган җирсез була алмый! Ә туган җир —илнең чишмә башы ул. Ишеттеңме? Табабыз авылыңны, тәгаен табабыз!* [Г. Бәширов, 2000: 106].

4. Алдагы мәгънә – җир өстендә аерым төбәк, урын. Автор «җир» сүзенең бу мәгънәсен *сугыш җирен* күз алдында тотып куллана.

*Сәҗидәнең вафатын ишетү Фәһимнең өстенә салкын су койгандай тәэсир итте, аны сискәндереп, тетрәтеп җибәрде. Ничек алай? Фәһим айкап кайткан сугыш җире түгел ләбаса монда! Анда гына үлем чалгысы аяусыз уңга да, сулга да селтәнә* [Г. Бәширов, 2000: 15].

*—Алай икән... Сугыш җиреннән кеше дуслашып кайта. Сезнең дә андый якташларыгыз бармы?* [Г. Бәширов, 2000: 159].

5. Тереклек булган, кешеләр яши торган җир йөзе .

*Мин дә эскадрон белән аларга каршы чабам, тулпарымның гыжылдавын ишетәм. Минем колагымда җил уйный, йөзләрчә атлының тоягы дөпелдәүдән җир үкерә* [Г. Бәширов, 2000: 303].

*Ничектер, нишләптер үзе белән бергә сугышка чыгып киткән иптәшләре исенә төште. Аларның күбесе Колчакка каршы сугышканда Урал, Себер якларында караңгы җир астында калды...*[Г. Бәширов, 2000: 85].

6. Билгеле бер халык, ил биләмәсе булган территория.

*Шунсыз булмас! «Балам чит-ят җирдә япа-ялгыз кала, нихәлләр итәр, ничек жан саклар?» — дип, үзәге өзелгәндер, «балакаем» дип, сине кочагына кыскандыр* [Г. Бәширов, 2000: 105].

*—Балакаем! Ана куеннарыннан мәхрүм калып, чит-ят җирләрдә үксез бала булып, кырыс кулларда иза чиккән бит ул, җанкисәгем!* [Г. Бәширов, 2000: 120].

7. Халыкның тормышы, көнкүреше яки тарихи вакыйгалар барышы белән характерлы булган урын, чагыштырмача зур булмаган гадәттә административ территория.

*—Шәһәр яшьләре клубларда, кичәләрдә очраша. Безнең авыл җирендә_аңа барып җителмәгән шул әле,— диде ул.— Очрашасы, сөйләшәсе килә...* [Г. Бәширов, 2000: 204].

*Әнәснең шахтада коногоннар, шахтерлар сүгенүен, шәһәр җирендә извозчиклар, ломовойлар, грузчиклар сүгенүен ишетеп хәйран калганы бар иде* [Г. Бәширов, 2000: 267].

8. Җир өсте; җирнең һава, атмосфера белән чикләнгән өслеге.

*Шул арада буран көчәйгән дә күк йөзен караңгы, калын болыт каплап алган. Бөтен дөнья тоташы белән үкерә, гүли, котырынган давыл юл читендәге әрәмәләрне, куакларны җиргә бөгә, җигүле атны, чанасындагы кешесе-ние белән очырып алып китәргә җилкенә иде* [Г. Бәширов, 2000: 342].

9. Җир шарының өске катлавы, үсемлекләр үсә, үсемлек тамырлары азык ала торган катлау, туфрак.

*Ул бичара, тилмереп көткәндер, ачыгуына чыдый алмыйча, баганасын кимергәндер! Тояклары канаганчы җир тырнагандыр, ахыр чиктә, хәле бетеп, егылгандыр, үлгәндер...* [Г. Бәширов, 2000: 240].

10. Иген үстерелә торган басу, чәчүлек кырлар.

*— Кызганыч, ни дип әйтик? Бар белән юк арасында. Россия — Европа түгел, артта калган ил: чабатасын да салмаган, электрның ни икәнен дә белми, җирне дә сука белән ермачлый...* [Г. Бәширов, 2000: 292].

Күргәнебезчә, “Җир” концепты катлаулы структура, бик күп компонентларны үзенә туплаган сүз. Татар халкының күренекле язучыларының берсе Г.Бәширов “җир” төшенчәсенә күп тапкырлар мөрәҗәгать итә, әсәрләрендә еш куллана һәм әлеге концептны тулырак күзалларга мөмкинлек бирә. “Җир” сүзен без карап үткән барлык мәгънәләрдә дә куллана, синонимнарын да еш файдалана. Туфрак, кыр, туган як, болын, басу кебек мәгънәләрне әсәрләрендә байтак очратырга була. *Актык минутларында да бик тыныч булды Гыйлаҗ. Язганы шулайдыр, аталы-уллы икебезгә дә туган туфрак куенына сыенырга насыйп булмады, сугыш кырында ятып калдык. Әнигә авыр булыр инде, зыярәт кылырга туган якта каберебез дә калмады,—диде* [Г.Бәширов, 2000: 68]. *Юк бит өмет заты, юк! Кап-кара үлем хәбәре генә!.. Гыйлаҗны сугыш кырында*

*җирләп кайтуга үзен дә гаепле сизгән сыман, егет башын иде* [Г.Бәширов, 2000: 67]. *Син, техникумны тәмамлап, бераз... шомарганнан соң, әниең Өммеһани апаның туган якларына барып, концерт бирерсең! Менә кайда калкып чыгачак синең туганнарың!* [Г.Бәширов, 2000: 322]. *Шуңа күрә әти мәрхүм әйтер иде: «Әгәр белеп эш итмәсәң, гөрләп чәчәк атып яткан болында тора-бара ат кузгалагы белән шайтан таягы, ким дигәндә, сукыр кычыткан гына тырпаеп калуы ихтимал», ди торган иде* [Г.Бәширов, 2000: 313]. *Ышанасы килми, әйеме! Алар безнең күз алдында иде бит, ызандашлар. Урак өстендә таң белән ин беренче булып басуга кем чыгып бара дисәң, Шакир абзыйныкылар булыр иде. Әйе!* [Г.Бәширов, 2000: 316].

Димәк, Г.Бәшировның "Гыйбрәт" романында "җир" концептын гаять күп очратырга була. Чөнки "җир" концепты, бигрәк тә матур әдәбият әсәрләрендә халыкның уй-кичерешләрен ачып бирүдә нык чагылыш таба. Шуңа күрә безнең тарафтан Г.Бәшировның "Гыйбрәт" романы сайлануы юкка түгел. Чөнки ул татар халкының психологиясен, эмоцияләрен, табигать күренешләрен, кеше күңеленең уйларын тирән чагылдыра ала торган язучы.

Кулланылган әдәбият


1. Бәширов Г. Гыйбрәт: тәмамланмаган роман / Г. Бәширов. – Казан: Татар китап нәшрияты, 2000. – 367 б.

2. Татар теленең аңлатмалы сүзлеге / төз. Ганиев Ф. – Казан: Тат. кит. нәшр., 2005. – 863 б.

3.Степанов Ю.С. Константы: опыт исследования / Ю.С.Степанов.- М.: "Языки русской культуры", 1997

4..Җамалетдинов Р.Р. Тел һәм мәдәният: Татар лингвокультурологиясе нигезләре / Р.Р.Җамалетдинов. – Казан: Мәгариф, 2006.


**Заявка на участие**

**1.** Хуснутдинов Дамир Хайдарович

**2.** Республика Татарстан, город Казань

**3.** –

**4.** –

**5.** 89046646819

**6.** –

**7.** -

**8.** Татарский государственный гуманитарно-педагогический университет, старший преподаватель кафедры общего сопоставительного языкознания факультета татарской филологии.

**9.** Заочная форма участия

**10.** Татар телендә “Җир” концепты (Г. Бәшировның “Гыйбрәт” романы нигезендә).